ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2020 п.г.т.Алексеевское № 433

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзү турында» 2018 елның 30 июлендәге 220 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль закон нигезендә 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы карары нигезендә кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзү турында» 2018 елның 30 июлендәге 220 номерлы башкарма комитет карарына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертергә:

«Кадыйров Н.К. – башкарма комитет җитәкчесе,
район комиссиясе рәисе»

сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга:

«Гайнуллин О.А. – башкарма комитет җитәкчесе,
район комиссиясе рәисе».

«Абакумов А.Н. – инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары,
комиссия рәисе урынбасары»

сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга:

«Гайсин М.Р. – инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**